**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 13 сентябрь № 639

г. Казань

2016 елга Татарстан Республикасы сәнәгатендә импорт алмаштыруны үстерү чаралары планы турында

«Татарстан Республикасында сәнәгать сәясәте турында» 2016 ел, 21 апрель, ТРЗ-24 нче Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. 2016 елга Татарстан Республикасы сәнәгатендә импорт алмаштыруны үстерү чаралары планын (карарга теркәлә) расларга.

2. Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнарының әлеге карарда күздә тотылган чараларны тормышка ашыруы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнарының штат саны һәм Татарстан Республикасы бюджетында каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 13 август, 639 нчы карары белән расланды

**2016 елга Татарстан Республикасы сәнәгатендә импорт алмаштыруны үстерү чаралары планы**

I. 2016 елга Татарстан Республикасы сәнәгатендә импорт алмаштыруны үстерү чаралары планының гомуми тасвирламасы

Татарстан Республикасы сәнәгатендә импорт алмаштыруны үстерү чаралары планы икътисадның реаль секторының тизләтелгән үсешен тәэмин итү һәм республика халкының тормыш сыйфатын күтәрү өчен Татарстан Республикасы территориясендә конкурентлыкка сәләтле импортны алмаштыра торган һәм импорттан алга киткән производстволар төзүгә һәм аларның эшләвенә булышлык күрсәтү максаты белән эшләнде.

Әлеге максатка ирешү түбәндәге төп бурычларны хәл итү юлы белән тәэмин ителәчәк:

сәнәгатьнең гражданнар тармакларында импортны алмаштыру буенча тармак планнарына кертелгән продукциянең өстенлекле төрләрен җитештерү проектларын Татарстан Республикасы предприятиеләрендә гамәлгә ашыруны стимуллаштыру;

Татарстан Республикасы территориясендә товарлар җитештерү (эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү) эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган оешмаларның төп капиталына инвестицияләр җәлеп итүгә булышлык күрсәтү;

перспективалы конкурентлык сәләтенә ия продукция җитештерү өчен модернизацияләү һәм яңадан техник җиһазландыру проектларын тормышка ашыруны стимуллаштыру;

чит ил партнерларын җәлеп итеп, Татарстан Республикасы предприятиеләрендә продукциянең өстенлекле төрләрен җитештерүне локальләштерү өчен уңай шартлар тудыру;

республиканың эшкәртүче тармаклардагы предприятиеләренең Россия һәм чит ил эре компанияләре белән кооперациясен үстерү;

инновацион технологияләр эшләүгә һәм гамәлгә кертүгә, Татарстан Республикасы предприятиеләренең интеллектуаль эшчәнлеге нәтиҗәләрен саклауга булышлык күрсәтү;

сәнәгатьнең эшкәртүче тармакларындагы предприятиеләрдә җитештерү нәтиҗәлелеген һәм хезмәт җитештерүчәнлеген арттыру буенча корпоратив программаларны тормышка ашыруга булышлык күрсәтү;

конкурентлыкка сәләтле производстволар төзү һәм үстерү проектларын фәнни яктан һәм кадрлар белән тәэмин итүне оештыру нәтиҗәлелеген арттыру;

югары өстәмә кыйммәтле продукция экспортын үстерүне стимуллаштыру.

Әлеге план кысаларында ярдәм чаралары күрсәтү өчен түбәндәгеләр өстенлекле санала:

импорт алмаштыру буенча федераль тармак планнарын тормышка ашыруда, шулай ук Россия импорт алмаштыру продукциясе җитештерүчеләре һәм Евразия икътисадый берлеге әгъзалары булган дәүләтләрнең җитештерүчеләре белән кооперация чылбырларында катнашучы сәнәгать өлкәсендәге эшчәнлек субъектлары проектлары;

гражданнар сәнәгатенең өстенлекле юнәлешләре буенча комплекслы инвестицион проектлар исемлегенә кертелгән проектлар;

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 30 декабрендәге 1312 нче һәм 2014 елның 3 гыйнварындагы 3 нче карарлары кысаларында финанслана торган гражданнар сәнәгатенең өстенлекле юнәлешләре буенча фәнни-тикшеренү һәм тәҗрибә-конструкторлык эшләрен күздә тоткан проектлар;

Россия Федерациясенең дәүләт программалары нигезендә гамәлгә ашырыла торган проектлар;

Татарстан Республикасының Инвестиция меморандумына кертелгән проектлар.

Әлеге проектлар реестрын алып баруны Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы гамәлгә ашыра.

## II. Контроль күрсәткечләр һәм индикаторлар

(процент)

| Соңгы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторы исеме | Индикаторларның мәгънәләре | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | 2015 ел | 2016 ел | 2017 ел | 2018 ел | 2019 ел | 2020 ел |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
| Сәнәгатьнең сәнәгать җитештерүе индексы | 100,4 | 101,3 | 105,2 | 103,0 | 102,7 | 107,2 |
| Эшкәртүче производстволарда сәнәгать җитештерүе индексы | 99,0 | 102,6 | 107,0 | 103,8 | 103,7 | 109,7 |
| Сәнәгать җитештерүенең гомуми күләмендә эшкәртүче производстволар өлеше | 70,0 | 70 | 71,9 | 72,3 | 72,5 | 72,8 |
| Эшкәртүче сәнәгатьтә югары җитештерүчәнлекле эш урыннары санының үсеш темпы | 103,0 | 104 | 105 | 106 | 107 | 108 |
| Татарстан Республикасы экспортының гомуми күләмендә чимал булмаган продукция өлеше | 60,2 | 61,2 | 61,7 | 62 | 62,5 | 63 |

III. Татарстан Республикасы сәнәгатендә импортны алмаштыра торган производстволар төзүне стималлаштыру чаралары комплексы

| Т/с | Чараның исеме | Көтелә торган нәтиҗә | Чараны тормышка ашыру вакыты | Үтәүче |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| | **1. Гомуми оештыру һәм норматив характердагы чаралар** | | | |
| Предприятиеләр кооперациясенең ресурслар һәм технологияләр чылбырларында катнашу өчен Татарстан Республикасы предприятиеләрен үстерү | | | | |
| 1. | Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының эре компанияләр сатып алуларыннан файдалана алуын тәэмин итү | Эшмәкәрлек субъектларының эре компанияләрнең сатып алулары турында хәбәрдарлыгы арту, шул исәптән кече һәм урта бизнес өчен smb.tattis.ru махсуслаштырылган бердәм ресурсыннан файдалану юлы белән. | 2016 ел дәвамында | Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы, Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы, «Татарстан Республикасының дәүләт заказы, инвестиция эшчәнлеге һәм төбәкара элемтәләр агентлыгы» дәүләт унитар предприятиесе, Татарстан Республикасы предприятиеләре һәм оешмалары (килешү буенча) |
| 2. | Республиканың эшкәртүче тармаклардагы предприятиеләренең Россия һәм чит ил эре компанияләре белән кооперациясен үстерү | «Россия тимер юллары» ачык акционерлык җәмгыяте, «Роснефть» нефть-газ компаниясе» гавами акционерлык җәмгыяте, «Лукойл» гавами акционерлык җәмгыяте, «Газпром» гавами акционерлык җәмгыяте, | 2016 ел дәвамында | Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы, Татарстан Республикасы предприятиеләре (килешү буенча) |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| | | «АВТОВАЗ» ачык акционерлык җәмгыяте, «Трансмашхолдинг» ябык акционерлык җәмгыяте, акционерлык җәмгыяте «Синара» төркеме» һ.б. кебек Россиянең иң эре компанияләренә Республиканың эшкәртүче тармаклардагы предприятиеләре продукциясен кайтартуны гамәлгә ашыру | | |
| Татарстан Республикасы сәнәгатен үстерүнең норматив базасын камилләштерү | | | | |
| 3. | Үзебезнең илдә конкурентлыкка сәләтле продукция җитештерүчеләрнең эшләү шартларын оптимальләштерү өчен Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының гамәлдәге норматив хокукый актларына үзгәрешләр кертү буенча тәкъдимнәр әзерләү | Татарстан Республикасынын сәнәгать предприятиеләре – конкурентлыкка сәләтле продукция җитештерүчеләрнең эшләве өчен уңай хокукый шартлар булдыру | 2016 ел дәвамында | Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы, Татарстан Республикасы предприятиеләре (килешү буенча) |
| Импортны алмаштыра торган производстволар төзү тематикасы буенча төбәкара һәм халыкара форумнарда катнашу | | | | |
| 4. | Республикадагы җитештерүчеләрнең Россия төбәкләрендә һәм чит илләрдәге партнерлар белән хезмәттәшлеген җайга салуда булышлык күрсәтү, шул исәптән делегацияләрнең үзара визитларын оештыру юлы белән | Татарстан Республикасының сәүдә партнерлары географиясен киңәйтү, Татарстан Республикасы предприятиеләре продукциясе экспортын арттыру | 2016 ел дәвамында | Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы, Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы, Татарстан Республикасы предприятиеләре (килешү буенча) |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| 5. | Россия Федерациясе субъектлары предприятиеләре белән адреслы хезмәттәшлекне җайга салу | Предприятиеләр үзләренең җитештерүендә куллана торган импорт продукциясен Россиядә җитештерүчеләр продукциясенә алмаштыру һәм Россия Федерациясе субъектлары предприятиеләре белән үзара продукция кайтартуларны гамәлгә ашыру | 2016 ел дәвамын-да | Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы, Татарстан Республикасы предприятиеләре (килешү буенча) |
| Продукцияне чит илләр базарларына чыгаруда булышлык күрсәтү | | | | |
| 6. | Татарстан Республикасы предприятиеләренә продукцияне чит илләр базарларына чыгаруда булышлык күрсәтү | Татарстан Республикасы предприятиеләре продукциясе экспорты үсеше. Татарстан Республикасы предприятиеләре продукциясен Россия Федерациясе сәүдә вәкиллекләре һәм Татарстан Республикасы вәкиллекләре аша үстерү | 2016 ел дәвамын-да | Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы, Татарстан Республикасы вәкиллекләре (килешү буенча), Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы |
| Күргәзмә чаралары, сәүдә-икътисадый миссияләр, конкурслар, бизнес-форумнар оештыру һәм аларда катнашу | | | | |
| 7. | Күргәзмә-конгресс чаралары, тармак форумнары, күргәзмәләре оештыру һәм Татарстан Республикасы предприятиеләренең аларда катнашуын тәэмин итү | Партнерлык мөнәсәбәтләрен җайга салу һәм Татарстан Республикасы предприятиеләре продукциясен үстерү | 2016 ел дәвамын-да | Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы, Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы, Татарстан Республикасы предприятиеләре һәм оешмалары (килешү буенча) |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| Кулланучылар сораган импортны алмаштыра торган товарларны күп форматта сатуны үстерү чараларын тормышка ашыру | | | | |
| 8. | Стационар булмаган сәүдәне үстерү өчен норматив хокукый документлар эшләү | Муниципаль милектә булган җирләрдә яки җир кишәрлекләрендә, шулай ук дәүләт милке чикләнмәгән җирләрдә һәм җир кишәрлекләрендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру тәртибен раслау;<br>бизнес-ширкәтләр, дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары вәкилләре катнашында Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Эшмәкәрлек советының тиешле проект төркеме эшчәнлеге кысаларында мобиль сәүдә оештыру тәртибен раслау | 2016 ел дәвамында | Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы, җирле үзидарә органнары белән берлектә Татарстан Респуб-ликасы Президенты кар-шындагы Эшмәкәрлек советы (килешү буенча) |
| 9. | Татарстан Республикасы җитештерүчеләренең ярминкәләрен үткәрү | Республикадагы товар җитештерүчеләрнең товарларын эчке базарга чыгару. Татарстан Республикасы халкын үзебездә җитештерелгән сыйфатлы товарлар белән тәэмин итү | 2016 ел дәвамында | Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы, җирле үзидарә органнары (килешү буенча), Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы |
| Мәгълүмат һәм консультация ярдәме күрсәтү | | | | |
| 10. | Сәнәгатькә дәүләт ярдәме күрсәтү программаларында катнашу мәсьәләләре буенча предприя- | Татарстан Республикасы предприятиеләрнең гамәлдәге дәүләт ярдәме чаралары турында | 2016 ел дәвамында | Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| | тиеләргә консультация бирү | хәбәрдар булуын тәэмин итү | | |
| | **2. Инвестиция проектларын тормышка ашыруда булышлык күрсәтү чаралары** | | | |
| Инвестицияләр өчен әзерләнгән инфраструктура төзү | | | | |
| 11. | Татарстан Республикасы территориясендә сәнәгать эшмәкәрлегенә ярдәм күрсәтү инфраструктурасын төзүдә һәм үстерүдә булышлык күрсәтү | Сәнәгать эшмәкәрлеген үстерү | 2016 ел дәвамында | Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы, Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы |
| 12. | Технологияләр импортын алмаштыруны үстерүдә булышлык күрсәтү | Югары технологияле эшләнмәләр өчен инфраструктура шартларын булдыру, беренче чиратта, инжиниринг үзәкләре прототиплаштыру үзәкләре төзү һәм үстерү | 2016 ел дәвамында | Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы, Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы |
| Инвестицияләрне җәлеп итү һәм хуплауның финанс механизмнарын формалаштыру | | | | |
| 13. | Татарстан Республикасының сәнәгатьне үстерү фонды эшләвен тәэмин итү | Татарстан Республикасы территориясендә сәнәгать житештерүен үстерүнең инвестиция проектларын тормышка ашыра торган предприятиеләр өчен финанс ресурсларыннан файдалана алу мөмкинлеген тәэмин итү | 2016 ел дәвамында | «Татарстан Республикасының Инвестиция-венчур фонды» коммерциячел булмаган оешмасы (килешү буенча) |
| 14. | Россия Сәнәгатьне үстерү фонды программаларында Татарстан | Татарстан Республикасы предприятиеләренең импортны | 2016 ел дәвамында | Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә ми- |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| | Республикасы предприятиеләренең катнашуын тәэмин итү | алмаштыру проектларын тормышка ашыру өчен Сәнәгатьне үстерү фонды акчасын җәлеп итү | | нистрлыгы, Татарстан Республикасы предприятиеләре (килешү буенча) |
| Инвестицияләрне салымнар белән стимуллаштыру | | | | |
| 15. | Инвестиция проектларын тормышка ашыру турындагы шартнамәләр нигезендә салым ташламалары ясауны тәэмин итү | Татарстан Республикасы территориясендә өстенлекле инвестиция проектларын тормышка ашыруда булышлык күрсәтү | 2016 ел дәвамында | Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы |
| 16. | «Чаллы» алга киткән социаль-икътисадый үсеш территориясе резидентларын җәлеп итү | «Чаллы» алга киткән социаль-икътисадый үсеш территориясендә инвестиция проектларын тормышка ашыру, моношәһәр икътисады диверсификациясе | 2016 ел дәвамында | Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы, Яр Чаллы муниципаль берәмлеге башкарма комитеты (килешү буенча), Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы |
| Инвестицияләр өчен уңай тариф шартлары тудыру | | | | |
| 17. | Россия Федерациясе субъектларында инвестицион климат торышы илкүләм рейтингының иң яхшы тәҗрибәләрен Татарстан Республикасында кертү | Татарстан Республикасына инвестицияләр җәлеп ителешен тәэмин итү | 2016 ел дәвамында | Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы, Татарстан Республикасы Инвестицион үсеш агентлыгы, Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы |
| Инвесторлар төзи торган производстволарны (кластерларны) кайтартучыларның тәэмин итүе | | | | |
| 18. | Татарстан Республикасы территориясендә сәнәгать кластерларын төзүдә булышлык күрсәтү | Сәнәгать өлкәсендәге эшчәнлек субъектлары тарафыннан сәнәгать кластерлары төзү инициа- | 2016 – 2017 еллар | Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы, Татарстан Рес- |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| | | тивасын белдерү. Татарстан Республикасы территориясендә сәнәгать кластерларын формалаштыру | | публикасы предприятиеләре (килешү буенча) |
| Инвестиция процессын кадрлар белән тәэмин итү | | | | |
| 19. | Татарстан Республикасында 2014 – 2020 елларга инвестиция проектлары нигезендә эшчәнлекнең структурасын үзгәртүне һәм модернизацияләүне гамәлгә ашыра торган оешмалар хезмәткәрләрен алдан һөнәри укытуны һәм өстәмә һөнәри белем бирүне оештыру (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 31 декабрь, 1099 нчы карары) | Татарстан Республикасы предприятиеләренең импортны алмаштыру буенча гамәлгә ашырыла торган проектларын квалификацияле кадрлар белән тәэмин итү | 2016 ел дәвамында | Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы, Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы, Татарстан Республикасы предприятиеләре (килешү буенча) |
| Инвесторлар төзи торган производстволар продукциясен сорауны стимуллаштыру | | | | |
| 20. | «Татарстан Республикасының иң яхшы товарлары һәм хезмәтләре» конкурсын үткәрү | Татарстан Республикасында җирле җитештерүчеләр товарларын сорауны арттыру | 2016 ел дәвамында | «Татарстан Республикасының иң яхшы товарлары һәм хезмәтләре» конкурсының оештыру комитеты |
| 21. | Татарстан җитештерүчеләре продукциясен сәүдә челтәр компанияләренә чыгару | Җирле товар җитештерүчеләрнең төяп җибәрелгән продукциясе күләмен арттыру | 2016 ел дәвамында | Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы, Татарстан Республикасы предприятиеләре (килешү буенча) |
| 22. | Татарстан Республикасы җитештерүчеләренең товарларын үстерү | Сатып алучыларның җирле продукцияне даими соравын | 2016 ел дәвамында | Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| | максаты белән «Татарстанныкын сатып ал!» акциясен үткәрү | формалаштыру | | коммуникацияләр агентлыгы (килешү буенча), Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы, Татарстан Республикасы Авыл хуҗа-лыгы һәм азык-төлек министрлыгы |
| 23. | Татарстан Республикасы предприятиеләрен Россия Федерациясенең тармак импортны алмаштыру планнарына кертүне тәэмин итү | Татарстан Республикасы предприятиеләрен тармак импортны алмаштыру планнарын үтәүчеләр рәтенә кертү | 2016 ел дәвамында | Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы, Татарстан Республикасы предприятиеләре (килешү буенча) |